Татарстан Республикасы
ЗАКОНЫ

«Яшьләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2005 елның 29 апреленда
кабул ителде

1 статья. «Яшьләр турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, №10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, №11), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

«Яшьләр һәм Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында

Татарстан Республикасы
ЗАКОНЫ

Әлеге Закон, Россия Федерациясендә дәүләт яшьләр сәясәтенең максатларыннан, принципларыннан һәм төп юнәлешләреннән чыгып, Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашырунын бурычларын, принципларын, төп юнәлешләрен һәм рәвешләрен билгели.

1 бүлек. **ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР**

1 статья. **Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр**

Әлеге Законда түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте — Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының яшьләрнең социаль үсеше,

аларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау өчен хокукый, социаль-икътисадый һәм оештыру шартларын булдыруга юнәлтелгән эшчәнлеге;

яшь гражданнар (яшьләр) — Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче 30 яшькә кадәрге затлар;

яшь гаилә — законнар нигезендә теркәлгән никахтан соң өч ел (гаиләдә бала булган очракта — никахның кайчан теркәлүенә бәйсез рәвештә) яшәгән, хатыны яисә ире 30 яшькә җитмәгән, шулай ук тулы булмаган балалы гаиләләрдә атасы яисә анасы 30 яшькә җитмәгән гаилә;

яшьләр иҗтимагый берләшмәләре — мәнфәгатьләр уртаклыгы нигезендә берләшкән 30 яшькә кадәрге яшь гражданнарның законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән берләшмәләре;

яшьләр өчен инфраструктура — дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру өчен кирәк булган объектлар (биналар, корылмалар, төзелмәләр), шулай ук яшь гражданнарның сәламәтлеген саклау, укыту, тәрбияләү, аларга психологик-педагогик, хокукый, реабилитация хезмәте күрсәтү, аларның физик, рухи һәм әхлакый үсешен, аларның эш белән тәэмин ителешен тәэмин итү һәм җәмгыяви ихтыяҗларын канәгатьләндерү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмалар системасы.

2 статья. **Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтенең бурычлары**

Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтенең бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

яшьләрне социаль һәм хокукый яклауны тәэмин итү;

яшь гражданнарга үз тормыш юлларын сайлау өчен хокукый, социаль-икътисадый, оештыру шартларын тудыру;

яшьләрнең социаль икътисадый җитлегүенә, аларны тәрбияләүгә һәм аларга белем бирүгә, аларның рухи һәм физик үсешенә булышлык итү;

яшьләр тарафыннан иҗтимагый әһәмияткә ия инициативаларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

дәүләт һәм җәмгыять үсеше мәнфәгатьләрендә яшьләрнең инновация мөмкинлеген гамәлгә ашыру;

сәламәт тормыш рәвешен булдыру, сәламәтлекне саклау, яшьләр мохитендә социаль-тискәре күренешләрне кисәтүне гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин итү;

яшьләрне җәмгыятьнең социаль-икътисадый, сәяси һәм мәдәни тормышына җәлеп итү һәм катнаштыру чаралары комплексын әзерләү һәм шулар өчен шартлар булдыру.

3 статья. **Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтенең принциплары**

Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте түбәндәге принципларга нигезләнә:

социаль-мәдәни, рухи, физик җитлегү, белем алу, социаль-һөнәри эшчәнлеккә керешү, гаилә кору, иҗтимагый әһәмияткә ия инициативаларны гамәлгә ашыру этабында яшь гражданнарга дәүләт ярдәме өстенлеге;

күрсәтелүче дәүләт ярдәменең дифференциацияләнгән һәм адреслы булуы;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының, физик һәм юридик затларның Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру эшчәнлеген координацияләү;

яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда төрле социаль институтларның көчләрен берләштерүне күздә тотучы системалы, комплекслы алым.

4 статья. **Дәүләт яшьләр сәясәте турында Татарстан Республикасы законнары**

Дәүләт яшьләр сәясәте турында Татарстан Республикасы законнары Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына нигезләнә һәм әлеге Законнан, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларыннан тора.

2 бүлек. **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ДӘҮЛӘТ ЯШЬЛӘР СӘЯСӘТЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУНЫҢ ТӨП ЮНӘЛЕШЛӘРЕ ҺӘМ РӘВЕШЛӘРЕ**

5 статья. **Мәгариф, тәрбия һәм үсеш өлкәсендә яшь гражданнарга дәүләт ярдәме**

Мәгариф, тәрбия һәм үсеш өлкәсендә яшь гражданнарга дәүләт ярдәменә түбәндәгеләр керә:

яшь гражданнарның интеллектуаль, әхлакый, физик үсешенә, аларны җәмгыятьнең мәдәни тормышында катнашуга җәлеп итүгә булышу чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

яшьләрне мәдәни һәм физик үстерү, патриотик һәм рухи-әхлакый тәрбияләү буенча республика программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

яшь гражданнарның хокукый культурасын үстерү чаралары системасын тормышка ашыру;

яшь гражданнарга белем алу өчен бертигез шартлар тудыру чараларын булдыру һәм гамәлгә ашыру;

яшьләргә өстәмә белем бирү системаларына ярдәм итү һәм аларны үстерү буенча республика программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

һөнәри белем бирү учреждениеләренең чыгарылыш укучыларын эш белән тәэмин итү, аларга тотрыклы, даими хезмәт эшчәнлегендә ярдәм итү чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

мәгариф, фән, техника һәм мәдәният өлкәсендә аеруча сәләтле яшь гражданнарны кызыксындыру чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

яшьләр иҗат эшчәнлегенең төрле юнәлешләре буенча смотрлар, конкурслар, олимпиадалар, фестивальләр, күргәзмәләр уздыру;

яшьләр оешмаларында, социаль реабилитацияләүгә мохтаж инвалид балалар өчен махсус укыту-тәрбия учреждениеләрен дә кертеп, мәгариф учреждениеләрендә тәрбия эшләренең төрле рәвешләренә ярдәм итү һәм аларны үстерү.

6 статья. **Сәламәтлек саклау, социаль-тискәре күренешләрне кисәтү, сәламәт тормыш рәвешен булдыру өлкәсендә яшьләргә ярдәм итү**

Сәламәтлек саклау, социаль-тискәре күренешләрне кисәтү, сәламәт тормыш рәвешен булдыру өлкәсендә яшьләргә ярдәм итү түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

физик культура, спорт, актив ял төрләре һәм туризм белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру;

яшьләрне савыктыру һәм аларның ялы буенча республика программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

яшьләргә хокукый һәм психологик-педагогик ярдәм чаралары комплексын гамәлгә ашыру;

яшьләр мохитендә социаль-тискәре күренешләрне кисәтү чараларын гамәлгә ашыру;

яшьләрне экологик агарту һәм табигатьне яклау, әйләнә-тирә мохит торышын саклау һәм яхшырту буенча гамәлләргә җәлеп итү;

яшьләр өчен инфраструктура учреждениеләрен булдыру һәм үстерү, яшь гражданнарга психологик-педагогик реабилитацияләү һәм ярдәм итү, социаль адаптацияләү өчен шартлар тудыру;

инвалид яшь гражданнарга физик культура, спорт белән шөгыльләнү өчен һәм аларны инвалидлар арасындагы массакүләм спорт төрләре буенча спорт ярышларында, турнирларында катнаштыруның махсус чараларын гамәлгә ашыру.

7 статья. **Яшь гражданнарның икътисадый мөстәкыйльлеген тәэмин итүгә һәм аларның хезмәт хокукларын гамәлгә ашыруга ярдәм итү**

Яшь гражданнарның икътисадый мөстәкыйльлеген тәэмин итүгә һәм аларның хезмәт хокукларын гамәлгә ашыруга ярдәм итү түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

яшьләрне эшкә урнаштыруны оештыру, яшь хезмәткәрләрне яңадан әзерләү, өстәмә эш урыннарын булдыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан законнар һәм башка норматив хокукый актлар эшләү, кабул итү һәм гамәлгә ашыру;

яшьләрне эшкә урнаштыруда, һөнәри яктан әзерләүдә, яшь хезмәткәрләрне производствода укытуда һәм яңадан әзерләүдә оешмаларның кызыксынучанлыкларын арттыручы икътисадый стимуллардан файдалану;

яшьләр эшкуарлыгына ярдәм итүнең дәүләт механизмнарын булдыру һәм гамәлгә ашыру;

инвалид яшь гражданнарны эш белән тәэмин итү буенча махсус чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру.

8 статья. **Яшьләрнең мораль-әхлакый кыйммәтләрен, патриотизм һәм граждан культурасын булдыру**

Яшьләрнең мораль-әхлакый кыйммәтләрен, патриотизм һәм граждан культурасын булдыруга түбәндәгеләр керә:

яшьләрнең рухи-әхлакый кыйммәтләрен, патриотизмын һәм граждан культурасын тәрбияләүгә юнәлдерелгән республика программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерү, яшьләр арасында тәрбия эшен оештыру мәсьәләре буенча сугыш һәм хезмәт ветераннарының иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлекне киңәйтү эше;

патриотик тәрбияне оештыру һәм уздыру буенча уку-укыту һәм махсус программалар, инновацион методикалар комплексын эшләү;

яшь гражданнарда патриотизм, үз тарихы белән горурлану, үз язмышлары өчен җаваплылык тәрбияли һәм үстерә торган программалар буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек;

экстремизм, социаль, милли һәм дини түзеп тора алмаучанлык идеяләрен таратуга каршы тору.

9 статья. **Яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме**

Яшь гаиләләргә дәүләт ярдәменә түбәндәгеләр керә:

яшь гаиләләр өчен мәгълүмати һәм консультатив хезмәт күрсәтүне оештыру;

яшь гаилә проблемалары буенча мониторинг үткәрү;

торак шартларын яхшыртуга мохтаж яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме мәсьәләре буенча Татарстан Республикасы законнарын камилләштерү.

10 статья. **Яшьләрнең һәм яшьләр җәмәгать берләшмәләренең иҗтимагый әһәмияткә ия инициативаларына булышлык**

Яшьләрнең һәм яшьләр җәмәгать берләшмәләренең иҗтимагый әһәмияткә ия инициативаларына булышлык түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

иҗтимагый яшәешнең барлык өлкәләрендә яшь гражданнарның һәм яшьләр җәмәгать берләшмәләренең ижади активлыгын, яшь гражданнарның потенциалын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру буенча иҗтимагый инициативаларына булышлык чараларын гамәлгә ашыру;

яшьләр җәмәгать берләшмәләре эшчәнлеген мәгълүмати һәм фәнни-методик тәэмин итү практикасын камилләштерү;

яшьләрне Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендәге консультатив эшчәнлегенә җәлеп итү буенча, яшьләр проблемалары буенча консультатив органнар булдыру практикасын һәм аларның эшчәнлеген киңәйтү буенча иҗтимагый инициативаларына булышлык чараларын стимуллаштыру;

яшьләр җәмәгать берләшмәләрен яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларын тикшерүгә җәлеп итү.

11 статья. **Яшьләр иҗтимагый берләшмәләренә дәүләт булышлыгы**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары яшьләр җәмәгать берләшмәләренә үз компетенциясе чикләрендә законнар нигезендә булышалар.

3 бүлек. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ДӘҮЛӘТ ЯШЬЛӘР СӘЯСӘТЕН ОЕШТЫРУНЫ ТӘЭМИН ИТҮ

12 статья. **Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләү**

Дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләүне Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр эшләре буенча махсус вәкаләтле органы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланучы нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

13 статья. **Яшьләр өчен инфраструктура**

Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары

законнар нигезендә яшьләр өчен яшь гражданнарның тормыш эшчәнлеген, аларга белем һәм тәрбия бирүне, аларны физик, рухи һәм әхлакый үстерүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән инфраструктура объектларын булдыруны һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итәләр.

14 статья. **Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен мәгълүмати һәм фәнни тәэмин итү**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары:

массакүләм мәгълүмат чаралары, шулай ук яшьләр өчен махсус мәгълүмат хезмәтләре аша яшь гражданнарга һәм яшьләр җәмәгать берләшмәләренә аларның хокуклары һәм бурычлары турында, яшьләр мәнфәгатьләренә кагылышлы уздырылучы чаралар турында, Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның барышы турында мәгълүмат бирәләр;

дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә фәнни эшләнмәләр һәм яшьләр хәле турында социологик тикшеренүләр уздыруны тәэмин итәләр.

15 статья. **Киңәшмә һәм эксперт органнары**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары каршында яшьләр җәмәгать берләшмәләренең, фәнни, мәгариф учреждениеләренен һәм башка оешмаларның вәкилләреннән һәм яшьләр проблемаларын өйрәнүдә һәм яшьләр арасында практик эш алып баруда махсуслашучы затлардан киңәшмә һәм эксперт органнары төзелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары каршысында төзелгән киңәшмә һәм эксперт органнарының вәкаләтләре, аларны оештыру һәм аларның эшчәнлеге тәртибе, персональ составы аларны төзегән әлеге органнар тарафыннан раслана.

16 статья. **Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү**

Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү чираттагы финанс елына бюджет турындагы Татарстан Республикасы Законында шушы максатлар өчен каралган акчалар, шулай ук законнар белән тыелмаган башка чыганаклар чикләрендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4 бүлек. **ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ**

17 статья. **Әлеге Законны бозган өчен җаваплылык**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм аларның урындагы затлары тарафыннан әлеге Законны үтәмәү йә тиешенчә үтәмәү законнарда билгеләнгән җаваплылыкка китерә.».

2 статья. Әлеге Закон, рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн узгач, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан, Кремль
2005 елның 26 мае

№ 73-ТРЗ